


Безнен героебыз vз гомерен педагогик хезмәткә багышлый. Педагог һәм остаз елында укытучылар турында кvбрәк сойләп, кvбрәк рәхмәтләребезне белдерик. Шул максат белән язылды бу язмам.
Газетабыз битләрендә vсеп килvче буынга белем, тәжрибә, коч, жан жылысы биргән кешеләр турында еш язабыз. Безнен язма геройлары Мордовиядә туган һәм vскән. Кече Ватанында хезмәт иткән бер чын патриот, бик тыйнак, гадел, ярдәмчел, туган ягын фидакарьләрчә яратучыларнын берсе – Светлана Шамиль кызы Абаева. Бу гажәеп хатын-кыз турында һаман яхшы сvзләр генә язасы килә. Ул искиткеч укытучы гына тvгел, ә искиткеч әни, ачык йозле хужабикә, чын дус та.
Светланага vзенен балачагы һәм әти - әнисе турында сойләвен сорагач, ул һәрвакыт әти-әнисе - Асма Исмәгыйль кызы белән Шамиль Ибраһим улы Абаевлар, дип горурланып әйтә. «Әти-әнием - гади авыл кешеләре, элеккечә әйткәндә - колхозчылар. Шунысы гажәп, әни белән әти дә 9 сыйныфны гына тәмамлаган. Әмма алар, олкән Сажидә апам белән мина лаеклы белем алу очен, әтием әйткәнчә «кеше булу» очен, барысын да эшләделәр. Ә балачагым минем меннәрчә яшьтәшләремнен тосле. Әмма бу минем очен бәхетле еллар иде», - ди С.Ш.Абаева.      Утыз тугыз ел тула анын педагогик стажына. 1984 елда Большие Поляны урта мәктәбен тәмамлаганнан сон, ул vзенен һонәри юлын олкән пионервожатый вазыйфасында туган мәктәбендә башлый. Светлана Шамиль кызы һәрвакыт ижтимагый эш белән шогыльләнә, авылда бер генә әһәмиятле чара да анын актив катнашыннан башка узмый. Ә Кадошкино районы Большие Поляны балаларынын ничә буынына ул татар теле һәм татар әдәбиятына, рус теле һәм әдәбиятына мәхәббәт тәрбияли, пионер чорындагы кvпме малай һәм кызларга кызыклы вакыйгаларга бай тормыш юлламасы бирә; аларнын остазы була. Мәктәптә эшне яратып, ботен кочен

биреп башкара ул.
Светлана Шамиль кызы М.Е.Евсевьев исемендәге МГПИнын филология факультетына укып, 1990 елда рус теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеге дипломын ала. Эшендә ул балаларны vзенә жәлеп итәргә, аларны кызыксындырырга, теге яки бу темага карата кызыксыну уятырга тырыша, эшне зур энтузиазм белән башкара. Шул вакыттан бирле кvп еллар узды, әмма С.Ш.Абаева vз vрнәгендә ана булачак һонәр сайлауда булышкан кешеләрне рәхмәт сvзләре белән искә ала. «Минем мәктәп еллары якты, бай булды, чонки мин активист. Һәрвакыт мәктәп вакыйгаларынын vзәгендә булдым. Ә минем нинди укытучыларым бар иде! Рус теле һәм әдәбиятын сыйныф житәкчесе Сәгыйдә Әхмәт кызы Ляпина алып барды. Математика - Ходайдан килгән педагог, энциклопедик белемле укытучы Сания Мохәммәтжан кызы Капкаева белем бирде. Алар, vзләре дә сизмичә, булачак педагогик һонәремә нигез салдылар, остазларым булдылар», - дип искә ала Светлана Шамиль кызы.
С.Ш.Абаева, актив педагог буларак, район һәм республика конкурсларында бик теләп катнашты. Нәтижәләр дә озак коттермәде - 1996 ел «Ел укытучысы» республика конкурсында оченче урын, 1998 елда – беренче урын. Ул конкурс турында шигырьләр дә (1998 елда) ижат иткән.
Анын сvзләренә караганда, яна эштә беренче адымнар ясарга менә дигән остазлар, дуслары булышкан. Укытучы хәзер дә һәр дәресне, анын планын жентекләп уйлый, укучыларга дәреслекләрдә кыскартылган әсәрләрне тулысынча укырга кинәш итә, классикага мәхәббәт тәрбияли, жавап вакытында укучы тулысынча ачылып, vз фикерен әйтә алсын очен тырыша. Светлана Шамиль кызынын белем бирә торган әдәбият һәм тел дәресләре бер сулышта уза: кызыклы һәм мавыктыргыч.
2007-2013 елларда Светлана Абаева Большие Поляны урта мәктәбе директоры була. «Мина ижади укытучылар коллективында эшләргә насыйп булды. Мин, хезмәттәшләрем, безнен укучыларыбыз район, кvп кенә республика, ә кайвакыт ботенроссия һәм халыкара конкурсларда, проектларда еш катнашып кына калмыйча, нәтижәләргә ирештек. Моны хәзер дә эшлибез».
2012 елдан бvгенге конгә кадәр С.Ш.Абаева - Большие Поляны топ мәктәбенен рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Анын укучылары рус әдәбияты һәм рус теле буенча олимпиадаларнын муниципаль турларында призлы урыннар яулыйлар; район, республика, ботенроссия конкурсларында берничә тапкыр жинvчеләр һәм призерлар булалар. Ул «Мәктәп патенты» халык-ара конкурсында берничә жинvчене әзерләде. Тырыш хезмәте анын лаеклы олы бvләкләр белән бәяләнде.
Педагог vз тәжрибәсе, белемнәре белән мәктәп, район укытучылары белән уртаклаша. Анын район семинарларында рус теле һәм әдәбияты укытучылары, педагогик советларда чыгыш ясавы шул турыда сойли.
С.Ш.Абаева - ижат кешесе. Ул матур шигырьләр яза. Районы һәм республика «Юлдаш» газетабыз белән актив хезмәттәшлек итә. Анын басмалары бик кызыклы портфолионы тәшкил итә. Язма героебыз кызы очен бишек жырын 2004 елда туган Катюшага багышлап язган. Тәрбиягә алган кыз очен ул әни булды һәм хәзер аннан башка vз тормышын кvз алдына да китерә алмый. Катюша - анын шатлыгы, омете. Бvгенге материалыбызнын героинясы жыр һәрвакыт яшәргә һәм ижат итәргә булышты, ди. Светлана Шамиль кызы кvп еллар рәттән, нигездә Большие Поляны мәктәбе педагогларыннан торган «Дуслык» татар жыры ансамблендә актив катнашкан.
С.Ш.Абаева - кин кvнелле кеше. Ярдәмгә килергә, ярдәм итәргә, тынларга әзер. Аны

хезмәттәшләре, укучылары кадерли, хормәт итә, яраталар, киңәш сорап ата-аналар еш мөрәҗәгать итә. Эштән соң аны ой эшләре һәм мәшәкатьләре котә. Алар һәр хатын-кызның да аз түгел, ә авылда яшәүчеләрнең бигърәк тә. Иң яраткан эшләрнең берсе - теплицада яшелчә үстерү. Күп хуҗабикәләр кебек үк, Светлана Шамиловна да тәмле итеп татар халык ашларын пешерергә ярата.
Светлана Шамиль кызы яңа планнар, бурычлар, максатлар белән яши. Нәрсә дә булса яңаны эшлисе, уй-ниятләрен тормышка ашырасы килә аның. Яшәргә, иҗат итәргә ярата һәм моңа ирешә!

**Наилә НАСЫРОВА**